**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «13» апреленнән № 154

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 24 ноябрендәге 504 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»**

«2016-2017 елларга коррупциягә каршы милли план турында» Россия Федерациясе Президентының 2016 елның 1 апрелендәге 147 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнехановның 2016 елның 1 апрелендәге 18277-МР номерлы йөкләмәсе нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 24 ноябрендәге 504 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- югарыда күрсәтелгән мунципаль программага түбәндәге эчтәлектәге 1.7. пункт өстәргә: «коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән очракта, законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру. Башкару вакыты: 2016-2017 еллар. Җаваплы: Темников В.В. – Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча)»;

- югарыда күрсәтелгән мунципаль программага түбәндәге эчтәлектәге 1.8. пункт өстәргә: «Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки

җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү очракларын ачыклау буенча эш алып бару юлы белән (күрсәтелгән таләпләрне үтәмәгән очракта, хәбәрдарлык бирергә һәм әлеге таләпләрне бозган затларга карата законнар белән каралган юридик җаваплылык чараларын кулланырга) муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турында закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү. Башкару вакыты: 2016-2017 еллар. Җаваплы: Савельева Л.А. – Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдире»;

- югарыда күрсәтелгән мунципаль программага түбәндәге эчтәлектәге 1.9. пункт өстәргә: «устав бурычы коррупциягә каршы көрәштә катнашу булган иҗтимагый берләшмәләр, иҗтимагый советларһәм граждан җәмгыятенең башка институтлары катнашында муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәү буенча оештыру, аңлату чаралары, шул исәптән бүләк алу, башка түләүле эшне башкаруга кагылышлы, коррупциячел хокук бозуларны кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгатьләр турында хәбәр итү бурычы комплексын эшләү. Башкару вакыты: 2016-2017 еллар. Җаваплы: Темников В.В. – Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча)»;

- югарыда күрсәтелгән мунципаль программага түбәндәге эчтәлектәге 3.5. пункт өстәргә: «Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Халык инвентаризациясе» акциясе үткәрү һәм ачыкланган бозуларны булдырмау һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен чаралар күрү. Башкару вакыты: 2016-2017 еллар. Җаваплы: Гордеева Н.А. – Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе»;

- югарыда күрсәтелгән мунципаль программага түбәндәге эчтәлектәге 4.8. пункт өстәргә:«муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы закон таләпләрен үтәүнең торышы һәм аны Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү Комиссиясе утырышында камилләштерү чаралары турындагы мәсьәләне ел саен тикшерүне тәэмин итү. Башкару вакыты: 2016-2017 еллар. Җаваплы: Темников В.В. – Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору

мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча)»;

- югарыда күрсәтелгән мунципаль программага түбәндәге эчтәлектәге 4.9. пункт өстәргә: «Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы эшләрне координацияләү комиссиясе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрү. Башкару вакыты: 2016-2017 еллар. Җаваплы: Темников В.В. – Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча)»;

- югарыда күрсәтелгән мунципаль программага түбәндәге эчтәлектәге 4.10. пункт өстәргә: «муниципаль хезмәткәрләрдә коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру буенча эш алып бару. Башкару вакыты: 2016-2017 еллар. Җаваплы: Савельева Л.А. – Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдире»;

- югарыда күрсәтелгән мунципаль программага түбәндәге эчтәлектәге 4.11. пункт өстәргә: «Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары алдына куелган бурычларны үтәү өчен төзелгән оешмаларда һәм учреждениеләрдә коррупцияне кисәтү буенча эш алып бару. Башкару вакыты: 2016-2017 еллар. Җаваплы: Темников В.В. – Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча)»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр белән идарә итүчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе-** **Р.Р. Фасахов**